**ГЛАВА ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Дубъязы, ул.Ленина, 28

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбьяз авылы, Ленин ур.,28

Тел./факс: +7(84365) 61-2-97, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30 ноябрь 2023 ел** **№15**

**Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Олы Солабаш гражданнарының үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, муниципаль район авыл җирлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә, Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге башлыгы КАРАР КЫЛДЫ::

1. 2023 елның 11 декабрендә 10 сәгать 00 минутка үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең Кече Сулабаш авылы адресы: Олы Солабаш авылы, Мухаметшин урамы, 19 йорт янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез ризамы:

1. 2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә.Муниципаль районның Дөбъяз авыл җирлегенең Кече Сулабашы, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

а) авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау

2. 2024 елда үзара салым түләүдән азат итү: а) өлешчә мобилизация чорында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә чакырылган гражданнарның гаилә әгъзалары б) 1 төркем инвалидлар

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының мәгълүмати стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә кабул ителгәннән соң 3 көн дәвамында.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Р.Ш.Галиуллин